ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17 07 2019 г. № 157

Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегендә 2019 елның III кварталына торак бинаның гомуми мәйданы бер квадрат метрына уртача базар бәясен раслау турында

Торак шартларын яхшырту буенча исәпкә куелган категория гражданнарга социаль түләүләр күләмен билгеләү, һәм аларга торак мәйданы сатып алуга (төзүгә) әлеге социаль түләүләр федераль бюджет чараларыннан бүлеп бирелгән очракта, шулай ук торак шартларын яхшырту буенча исәпкә куелган гражданнар өчен файдаланылучы башка хисапларны билгеләү максатларында, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Россия Федерациясе буенча 2019 елның икенче яртыеллыгына торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе һәм Россия Федерациясе субъектлары буенча 2019 елның III кварталына торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры уртача базар бәясе нормативы турында» 2019 елның 21 июнендәге 353/пр номерлы боерыгына таянып, карар бирәм:

1. Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегендә 2019 елның III кварталына торак бинаның гомуми мәйданы бер квадрат метрына уртача базар бәясен 50 165 (илле мең бер йөз алтмыш биш сум) күләмендә расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәре Башкарма комитетының Торак сәясәте бүлеге җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы А.В. Хәнәфиевага йөкләргә.

Җитәкче Д.И. Баландин